ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 19 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 1 пунктта «хәрби хезмәт һәм хезмәт спорт төрләре буенча ярышлар оештыручы» сүзләрен «хәрби-гамәли һәм хезмәти-гамәли спорт төрләрен үстерүдә катнашучы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 6 пунктта «тренер-укытучылар (алга таба шулай ук – тренерлар)» сүзләреннән соң «, спорт медицинасы буенча белгечләр» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) хәрби-гамәли һәм хезмәти-гамәли спорт төрләрен үстерүгә ярдәм күрсәтергә.»;

3) 12 статьяда:

а) 10 өлештә «хәрби-гамәли һәм хезмәти-гамәли спорт төрләре» сүзләрен «хәрби-гамәли һәм (яисә) хезмәти-гамәли спорт төрләре» сүзләренә алмаштырырга, «хәрби-гамәли һәм хезмәти-гамәли спорт төрләрен» сүзләрен «хәрби-гамәли һәм (яисә) хезмәти-гамәли спорт төрләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Татарстан Республикасы территориясендә чемпионат, кубок яисә беренчелек статусы һәм атамасы булган хәрби-гамәли һәм (яисә) хезмәти-гамәли спорт төре буенча рәсми спорт ярышын оештыру һәм үткәрү әлеге спорт ярышын оештыручылар составына тиешле хәрби-гамәли һәм (яисә) хезмәти-гамәли спорт төрләрен үстерүгә җитәкчелек итә торган федераль башкарма хакимият органын кертү шарты белән генә рөхсәт ителә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «в» пунктчасыннан тыш, 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «в» пунктчасы әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 29 апрель
№ 23-ТРЗ